КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

2022 ел, 7 ноябрь г.Казань № б-2421

Казан шәһәрендә 2023 елгы Махсус Олимпиаданың Бердәм Уеннарын әзерләгәндә һәм үткәргәндә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, башкарма хакимият федераль органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнары, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары, оешмалар һәм иҗтимагый берләшмәләр хезмәттәшлеген оештыру максатларында:

1. Казан шәһәрендә 2023 елгы Махсус Олимпиаданың Бердәм Уеннарын әзерләү һәм үткәрү буенча республика оештыру комитетын төзергә.

2. Түбәндәгеләрне (боерыкка теркәләләр) расларга:

Казан шәһәрендә 2023 елгы Махсус Олимпиаданың Бердәм Уеннарын әзерләү һәм үткәрү буенча республика оештыру комитеты турындагы нигезләмәне;

Казан шәһәрендә 2023 елгы Махсус Олимпиаданың Бердәм Уеннарын әзерләү һәм үткәрү буенча республика оештыру комитеты составын.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2022 ел, 7 ноябрь, б-2421 нче
боерыгы белән расланды

# Казан шәһәрендә 2023 елгы Махсус Олимпиаданың Бердәм Уеннарын әзерләү һәм үткәрү буенча республика оештыру комитеты турында нигезләмә

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Казан шәһәрендә 2023 елгы Махсус Олимпиаданың Бердәм Уеннарын әзерләү һәм үткәрү буенча республика оештыру комитеты (алга таба шул ук эзлеклелектә – Уеннар, республика оештыру комитеты) Уеннарны әзерләгәндә һәм үткәргәндә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, башкарма хакимият федераль органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнары (алга таба – башкарма хакимиятнең территориаль органнары), Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары (алга таба – җирле үзидарә органнары), оешмалар һәм иҗтимагый берләшмәләр хезмәттәшлеген оештыру максатларында төзелгән коллегиаль орган булып тора.

1.2. Республика оештыру комитеты үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы законнарына, шулай ук бу Нигезләмәгә таянып эш итә.

## II. Республика оештыру комитетының төп бурычлары

2.1. Республика оештыру комитетының төп бурычлары – республика оештыру комитеты тарафыннан кабул ителгән карарларны тормышка ашыру барышында Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, башкарма хакимиятнең территориаль органнары, җирле үзидарә органнары, оешмалар һәм иҗтимагый берләшмәләр хезмәттәшлеген тәэмин итү һәм аларның нәтиҗәлелеген бәяләү.

2.2. Республика оештыру комитеты үз алдында торган бурычларны тормышка ашыру максатларында түбәндәгеләргә хокуклы:

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарыннан, башкарма хакимиятнең территориаль органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, оешмалардан һәм иҗтимагый берләшмәләрдән законнар нигезендә республика оештыру комитеты компетенциясенә кагылышлы мәсьәләләр буенча мәгълүмат материалларын соратып алырга;

кирәк булган очракта, республика оештыру комитеты компетенциясенә кагылышлы мәсьәләләрне хәл итү өчен оператив штаб, эшче төркемнәрне билгеләнгән тәртиптә төзергә;

үз утырышларына Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, башкарма хакимиятнең территориаль органнары, җирле үзидарә органнары, оешмалар, иҗтимагый берләшмәләр җитәкчеләрен һәм вәкилләрен, башка кызыксынучы затларны билгеләнгән тәртиптә чакырырга;

Уеннарны әзерләү һәм үткәрү мәсьәләләре буенча киңәшмәләрдә, конференцияләрдә һәм семинарларда катнашу өчен үз вәкилләрен җибәрергә.

III. Республика оештыру комитеты составы

3.1. Республика оештыру комитеты Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты боерыгы нигезендә төзелә.

3.2. Республика оештыру комитеты рәисе – Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары. Рәис вакытлыча булмаган чорда аның вазифаларын, рәис кушуы буенча, рәис урынбасарларының берсе башкара.

3.3. Республика оештыру комитеты рәисе:

республика оештыру комитеты эше белән җитәкчелек итә, мәсьәләләр исемлеген, аларны республика оештыру комитеты утырышларында карау срокларын һәм тәртибен билгели;

республика оештыру комитеты рәисе урынбасарлары һәм әгъзалары арасында вәкаләтләрне (вазифаларны) бүлә;

утырышларның көн тәртибен, аны үткәрү датасын, урынын һәм вакытын билгели һәм раслый;

республика оештыру комитеты утырышлары беркетмәләренә һәм аның башка документларына кул куя.

3.4. Республика оештыру комитеты секретаре:

республика оештыру комитеты утырышын үткәрүгә кадәр кимендә биш көн кала әгъзаларга утырышны үткәрү урыны, датасы, вакыты турында хәбәр итә, утырышның көн тәртибен җибәрә;

Республика оештыру комитетының утырышлар беркетмәләрен һәм башка документларын әзерләү өчен җавап бирә.

3.5. Республика оештыру комитеты әгъзалары:

республика оештыру комитеты һәм аның рәисе йөкләмәләрен үти;

республика оештыру комитеты компетенциясендәге мәсьәләләр буенча тәкъдимнәрне тикшерүгә чыгара;

республика оештыру комитеты тарафыннан карала торган мәсьәләләр буенча материаллар белән таныша;

республика оештыру комитеты карарларын әзерләү, үтәү, аларның үтәлешен контрольдә тоту буенча кирәкле чараларны башкара.

IV. Республика оештыру комитеты утырышлары һәм карарлары

4.1. Республика оештыру комитеты утырышларын рәис яки аның кушуы буенча рәис урынбасарларының берсе алып бара.

4.2. Республика оештыру комитеты утырышы, әгәр анда әгъзаларының яртысыннан күбрәге катнашса, тулы хокуклы дип санала. Республика оештыру комитеты карары, әгәр аның өчен утырышта катнашкан әгъзаларның яртысыннан да ким булмаган өлеше тавыш бирсә, кабул ителгән дип санала. Тавыш биргәндә тавышлар тигез булган очракта, рәислек итүченең тавышы хәлиткеч була.

4.3. Республика оештыру комитеты утырышында мәсьәләләрне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча карарлар кабул ителә, алар беркетмә белән рәсмиләштерелә.

Республика оештыру комитеты утырышы берткетмәсенә рәислек итүче тарафыннан кул куела.

4.4. Кирәк булганда, республика оештыру комитеты рәисе карары буенча республика оештыру комитетының чираттан тыш утырышлары үткәрелергә мөмкин.

4.5. Көн тәртибе мәсьәләләре буенча материаллар республика оештыру комитеты утырышларына республика оештыру комитеты секретаре тарафыннан билгеләнгән утырыш датасына кадәр 10 эш көненнән дә соңга калмыйча тапшырыла. Секретарь кергән материаллар нигезендә республика оештыру комитеты утырышының көн тәртибе проектын төзи һәм аны, утырыш көненә кадәр биш эш көненнән дә соңга калмыйча, республика оештыру комитеты рәисенә раслауга кертә.

4.6. Утырышның көн тәртибе республика оештыру комитеты рәисе тарафыннан раслана. Аны раслаганнан соң, утырышның көн тәртибенә үзгәрешләр кертү бары тик республика оештыру комитеты рәисе карары белән мөмкин була. Бу очракта, республика оештыру комитеты секретаре республика оештыру комитеты рәисе күрсәтмәсе буенча утырышның көн тәртибенә үзгәрешләр кертә һәм бу хакта республика оештыру комитеты әгъзаларына хәбәр итә.

4.7. Утырышта республика оештыру комитеты әгъзасы булмаган очракта, структур бүлекчә башлыгыннан түбән булмаган дәрәҗәдәге алмаштыручы затка катнашырга рөхсәт ителә.

4.8. Республика оештыру комитеты тарафыннан кабул ителә торган карарлар агымдагы эшчәнлекне гамәлгә ашырганда кулланып эш итү өчен Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына, башкарма хакимиятнең территориаль органнарына, җирле үзидарә органнарына, оешмаларга һәм иҗтимагый берләшмәләргә, башка кызыксынучы затларга җибәрелә.

## V. Республика оештыру комитеты эшчәнлеген тәэмин итү

5.1. Республика оештыру комитеты эшчәнлеген матди-техник яктан, документлар, мәгълүмат, транспорт, финанс һәм башкалар белән тәэмин итү Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

5.2. Республика оештыру комитеты эшчәнлеген оештыру ягыннан тәэмин итү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының тиешле структур бүлекчәләре тарафыннан гамәлгә ашырыла.

___

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2022 ел, 7 ноябрь, б-2421 нче
боерыгы белән расланды

Казан шәһәрендә 2023 елгы Махсус Олимпиаданың Бердәм Уеннарын
әзерләү һәм үткәрү буенча республика оештыру комитеты
составы

| | |
|---|---|
| Фазлыева Ләйлә Ринат кызы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары, республика оештыру комитеты рәисе |
| Леонов Владимир Александрович | Татарстан Республикасы спорт министры, республика оештыру комитеты рәисе урынбасары |
| Сәгыйтова Гүзәл Рәмзил кызы | Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары, республика оештыру комитеты рәисе урынбасары (килешү буенча) |
| Денисов Максим Сергеевич | «Спорт һәм социаль проектлар дирекциясе» коммерциягә карамаган автоном оешмасы генераль директоры, республика оештыру комитеты секретаре (килешү буенча) |

Республика оештыру комитеты әгъзалары

| | |
|---|---|
| Абашев Әлмир Рәшид улы | Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министрының беренче урынбасары |
| Алибаев Тимур Лазович | «А.Н.Туполев исемендәге Казан илкүләм тикшеренү техник университеты – КАИ» югары белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе ректоры вазифаларын башкаручы (килешү буенча) |
| Әсәдуллина Алсу Мөнип кызы | Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры урынбасары |
| Әхмәтова Эльвира Фәнис кызы | Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесенең беренче урынбасары |
| Богомолов Станислав Юрьевич | Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Казан транспорт линия идарәсе башлыгы (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Борһанов Рафис Тимерхан улы | «Идел буе дәүләт физик культура, спорт һәм туризм университеты» югары белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе ректоры (килешү буенча) |
| Вәлиев Айрат Рәсим улы | «Казан дәүләт аграр университеты» югары белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе ректоры (килешү буенча) |
| Вахитов Радик Рәфыйк улы | Россия Федерациясе Тышкы эшләр министрлыгының Казан шәһәрендәге вәкиле (килешү буенча) |
| Воронцов Андрей Юрьевич | Россия Федерациясе Федераль куркынычсызлык хезмәтенең Саратов һәм Самара өлкәләре буенча чик буе идарәсенә караган «Идел буе» чик буе контроле отрядының «Казан-аэропорт» тикшереп үткәрү пункты башлыгы (килешү буенча) |
| Гәрәев Марат Мәсгут улы | Татарстан таможнясы башлыгы (килешү буенча) |
| Гомәров Рөстәм Фәрит улы | Россия Федерациясе Милли гвардия гаскәрләре федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсе башлыгы (килешү буенча) |
| Зарипова Эльмира Әмир кызы | Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры |
| Захарова Светлана Михайловна | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитеты рәисе (килешү буенча) |
| Казаков Юрий Михайлович | «Казан илкүләм тикшеренү технологик университеты» югары белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе ректоры вазыйфаларын вакытлыча башкаручы (килешү буенча) |
| Карпов Родион Михайлович | Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры урынбасары |
| Кудряшев Владимир Николаевич | Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры урынбасары |

| | |
|---|---|
| Лебедев Егор Витальевич | «Россия Махсус Олимпиадасы» акыл үсеше артта калган инвалидларга ярдәм күрсәтү буенча гомумроссия иҗтимагый хәйрия оешмасы генераль директоры (килешү буенча) |
| Мәхмүтов Илдар Сәйфулла улы | «Казан» таудан чаңгы шуу спорт-савыктыру комплексы» акционерлык җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |
| Мөхәммәтҗанов Фәргать Госман улы | Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының җәмәгать тәртибен саклау буенча полиция башлыгы урынбасары (килешү буенча) |
| Натфуллин Дамир Данил улы | Татарстан Республикасы мәдәният министры урынбасары |
| Парфенова Лариса Анатольевна | «Россия Махсус Олимпиадасы» акыл үсеше артта калган инвалидларга ярдәм күрсәтү буенча гомумроссия иҗтимагый хәйрия оешмасының Татарстан республика төбәк бүлеге рәисе (килешү буенча) |
| Патяшина Марина Александровна | Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеген саклау өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсе җитәкчесе (килешү буенча) |
| Разинов Борис Николаевич | Элемтә, мәгълүмат технологияләре һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсе җитәкчесе (килешү буенча) |
| Романцов Сергей Анатольевич | «Казан» халыкара аэропорты» акционерлык җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |
| Садыйков Айрат Халит улы | Татарстан Республикасы транспорт һәм юл хуҗалыгы министры урынбасары |
| Салихов Марат Мансур улы | «Универсиада авылы» Татарстан Республикасы дәүләт автоном учреждениесе директоры (килешү буенча) |
| Сафина Гөлнара Марат кызы | Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты рәисе урынбасары |

| | |
|---|---|
| Суржко Николай Владимирович | Татарстан Республикасы гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министры урынбасары (килешү буенча) |
| Уразов Максим Сергеевич | Россия Федерациясе Спорт министрлыгының Физик культура һәм массакүләм спорт департаменты директоры (килешү буенча) |
| Фәрдиев Илшат Шәех улы | «Сетевая компания» акционерлык җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |
| Хәйруллин Айрат Ринат улы | Татарстан Республикасы дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министры |
| Хвостиков Игорь Владимирович | Россия Федерациясе Федераль куркынычсызлык хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе башлыгы (килешү буенча) |
| Царев Леонид Сергеевич | «Баш радиоешлык үзәге» федераль дәүләт унитар предприятиесенең Идел буе федераль округындагы филиалының Татарстан Республикасы буенча идарәсе башлыгы (килешү буенча) |
| Шакирова Гүзәл Рәис кызы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Сәламәтлек саклау, спорт һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру мәсьәләләре идарәсе башлыгы |
| Якубов Таһир Миһдәт улы | «Россия тимер юллары» ачык акционерлык җәмгыятенең Горький төбәк тимер юл вокзаллары дирекциясе башлыгы урынбасары (килешү буенча). |